Тубэн Оскебаш авыл җирлеге
Советы

КАРАР

04 февраль 2026ел №2

Гектарларда яисә баллогектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 2.1 пункты, 19.1 статьясындагы 8 – 11 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гектарларда яисә балло-гектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1475 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Тубэн Оскебаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан 2025 елның 25 декабрендәге өземтәләргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубэн Оскебаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Кадастр номеры 16:26:000000:358, мәйданы 1064198 м2, урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Тубэн Оскебаш авыл җирлеге, җирләр категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, рөхсәт ителгән куллану төре: авыл хужалыгы жирлэре, гектарларда күрсәтелгән, гади ялгыз вакланма рәвешендә, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә булган җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукында өлешләр күләмен билгеләү нәтиҗәләрен расларга.

3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Тубэн Оскебаш авылы башкарма комитетына, әлеге карар басылып чыккан көннән соң 30 көн узгач, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тубэн Оскебашавыл җирлеге башлыгы Н.М.Мохэммэтжанов